

Машина йортvче профессиясе юлларда беренче тәгәрмәчле vзе йори торган арбалар барлыкка килгәннән бирле хөрмәттә. Елдан-ел автомобильләр vзгәрә, анын белән бергә шофер профессиясе дә vзгәрә, шомара бара. Яшь булсалар да, тәжрибәле Марат Алешев, Шамиль Кильдеев һәм Марат Капкаев Кадошкино районы администрациясе гаражындагы 7 торле автотранспортны «жигәләр» егетләр.      Хужалыкнын ин фидакарь, тырыш, тәжрибәле хезмәткәрләре бу оч егет. Эш тәжрибәләре егермешәр ел инде аларнын. Кечкенәдән vк техника арасында уралып vскән малайларнын куллары теләсә кайсына ятып тора. Ике дистә ел эчендә йок машиналары, автобуслар һәм жинел машиналарнын рульләрен әйләндерергә туры килгән аларга.
Администрация машина паркына алар бер ук вакытта киләләр дип тә әйтергә момкин һәм шул вакытта ук нык коллектив та формалаша. Кирәк булса, бер-берсенә ярдәмгә “әйт” дигәндә килеп житәләр. Эшләре vзенчәлекле. Хезмәтләре башка шоферларныкыннан аермалы. Нәрсә белән диярсез - юл бит бер һәм баранка да! Жавап берничә олештән тора. Беренчедән, транспортнын теләсә кайсы торендә дә бер-берсен алыштыра алалар, икенчедән, vз урыннарында - белгечләр, оченчедән, Мордовиядәге һәрбер районны, шәһәрне, урамны белә Марат Алешев, Шамиль Кильдеев һәм Марат Капкаев. Чонки алар – район һәм республика кvләмендә vткән һәрбер чарада катнашалар. Катнашалар дип, чараларда катнашучыларны вакытына исән-имин алып баралар һәм кайтарып куялар. Районнын торле административ хезмәткәрләрен дә торле йомышлары белән башкалабызнын берьюлы торле оешмаларына алып киләләр. Экскурсияләргә дә чыгалар. Биредә маршрутны белv таләп ителә, ягулык һәм вакытны да vлчи белv шарт. Әле бит аларны котеп торулары ни тия! Бер кешене дә югалтырга ярамый бит. Чыдамлылар алар. Бик унган, тырыш, халык белән тиз арада уртак тел дә таба беләләр, жаваплы кешеләр: аларнын  машиналары һәрвакыт тозек, чиста, юлга чыгарга әзер.Унышларынын нигезендә туган жиргә, vз эшенә булган мәхәббәт ята. Алар туган якларын ташлап, бәхет эзләп әллә кайларга китмиләр. Кендек каны тамган жирдә топләнеп, нигез коралар, тату гаиләләрендә балалар тәрбиялиләр. Менә шулай Мордовия юлларын яхшы белгән, булдыклы шоферлар - Марат Алешев, Шамиль Кильдеев һәм Марат Капкаев яшиләр һәм хезмәт итәләр.

Наилә Насырова